**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның " 26" февраленнән № 6-32

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә"не яңа редакциядә кабул итү турында"гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 9 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Башкарма комитет вәкаләтләре» исемле 4 бүлегендәге 4.1 пунктның 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 13 һәм 14 абзацлар өстәргә:

" - 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» гы Федераль закон нигезендә җирлек территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыра;

- авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслый, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планнарын бирә, төзелешкә рөхсәт бирә ( Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлекләр территориясендә урнашкан төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирә, авыл җирлекләренең шәһәр төзелеше проектлавы буенча җирле нормативларны раслый, муниципаль ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен авыл җирлекләре чикләрендә җирләр резервлый һәм җир кишәрлекләрен аерып ала, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы тарафыннан каралган очракларда, биналарны, корылмаларны күзәтүләрне башкара һәм тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында тәкъдимнәр бирә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән төзү яки реконструкцияләү планлаштырылган индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортының параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турындагы хәбәрнамә (алга таба-планлаштырыла торган төзелеш турында

хәбәрнамәне) җибәрә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән төзү яки реконструкцияләү планлаштырылган индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортының параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге булмау турындагы хәбәрнамә (алга таба-планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәне) җибәрә, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектларының яки бакча йортларының төзелеше яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр җибәрә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, территорияне планлаштыру документлары яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән тәңгәлләштерү турында карарлар кабул итә (алга таба шулай ук-билгеләнгән таләпләргә туры китерү), максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра.»;

- «Башкарма комитет вәкаләтләре» 4 бүлегендәге 4.1 пунктындагы 5 пунктчасының 10 абзацына түбәндәге сүз өстәргә: "(волонтерлыкка);»;

- «Башкарма комитет вәкаләтләре» 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 5 пунктчасының 12 абзацында түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

" - коммуналь инфраструктура системасына тоташуга тарифларны, коммуналь комплекс оешмаларының тоташтыруга тарифларын, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларга өстәмәләрне, кулланучылар өчен бәяләргә (тарифларга) өстәмәләрне җайга сала;»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 7 пунктчасының 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен ныгытуга, милләтара һәм конфессияара бердәмлекне ныгытуга, аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны эшләүне һәм тормышка ашыруны тәэмин итә;»;

- «Башкарма комитет вәкаләтләре» исемле 4 бүлегендәге 4.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:

«- «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын тормышка ашыра»;

- "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында" Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыра»;

- авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр башкаруны оештыра һәм Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан расланган халыкны кабул итү графигы нигезендә нотариус тарафыннан халыкны кабул итүне гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтә;

- каты коммуналь калдыклар җыелу урыннарын (мәйданчыкларын) булдыра һәм карап тотуны үз өстенә ала, мондый бурыч Российской Федерациясе закончалыкларында билгеләнгән башка затларда булган очраклардан тыш;

- каты коммуналь калдыклар җыелу урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру схемасын билгеле һәм каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын алып бара;

- экологик тәрбия бирүне оештыра һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик культура формалаштыра;

- муниципаль янгын саклау бүлеген булдыра.».

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 13.11.2019 елдагы 54-338 номерлы карарының 1 пунктындагы 5, 6 пунктчаларын төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы 18.03.2015 ел, № 42-248 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы 2020 ел, 8 декабрь, 3-22 нче карары үз көчен югалткан дип санарга

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында» htt:/pravo. tatarstan. ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru батырып чыгарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллеге органнары белән үзара хезмәттәшлек итү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләнә

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы

В. М. Козлов